ГОРОДСКОЙ СОВЕТ
МУНИЦИПАЛЬНОГО ОБРАЗОВАНИЯ
ГОРОД НАБЕРЕЖНЫЕ ЧЕЛНЫ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЯР ЧАЛЛЫ ШӘҺӘРЕ
МУНИЦИПАЛЬ БЕРӘМЛЕГЕ
ШӘҺӘР СОВЕТЫ

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

9 ноябрь, 2016 ел № 11/7

Шәһәр Советының 2008 елның 25 сентябрендәге «Эшчәнлекнең аерым төрләре өчен йөкләнгән keremгә берләшкән салым рәвешендәге салым салу системасы турында» 34/5 санлы Карарына үзгәрешләр кертү хакында

Россия Федерациясе Бюджет кодексы, 2016 елның 3 июлендәге «Россия Федерациясе Салым кодексының икенче өлешенә үзгәрешләр кертү турында» 248-ФЗ санлы Федераль закон, шәһәр Уставының 28 маддәсе нигезендә

Шәһәр Советы

КАРАР бирде:

1. Шәһәр Советының 2008 елның 25 сентябрендәге «Эшчәнлекнең аерым төрләре өчен йөкләнгән керемгә берләшкән салым рәвешендәге салым салу системасы турында» 34/5 санлы Карарына (Шәһәр Советының 2009 елның 22 октябрендәге 43/5, 2010 елның 15 ноябрендәге 4/6, 2011 елның 25 августындагы 13/6, 2011 елның 27 октябрендәге 14/4, 2012 елның 20 декабрендәге 22/11 санлы Карарлары редакциясендә) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 2 пунктның 1 пунктчасында «Гомумроссия халыкка хезмәт күрсәтү классификаторы нигезендә классларга бүленгән төркемнәре, төркемчәләре, төрләре һәм (яки) аерым көнкүреш хезмәтләрен» сүзләрен төшереп калдырырга;

2) кушымтаның 1 пунктын әлеге Карарга кушымта нигезендә яңа редакциядә бәян итәргә.

2. Әлеге Карар 2017 елның 1 гыйнвареннән үз көченә керә, ләкин рәсми басылып чыккан көннән соң бер айдан да иртә түгел.

3. Әлеге Карар үтәлешен тикшереп торуны Шәһәр Советының социаль-икътисадый үсеш мәсьәләләре һәм бюджет буенча даими комиссиясенә йөкләргә.

Шәһәр Хакиме Н.Г. Мәһдиев

Шәһәр Советының
11/7 нче Карарына
кушымта
9 ноябрь, 2016 ел

К2 нигез керемнең төзәтмә кертү коэффициенты зурлыгы

| Тәртип саны | Эшмәкәрлек эшчәнлеге төрләре | К2 |
|---|---|---|
| 1. | Көнкүреш хезмәте күрсәтү: | |
| | – зәркан әйберләрне төзәтү, халыкның шәхси заказы буенча зәркан әйберләр һәм охшаш әйберләр җитештерү | 1,0 |
| | – электрон көнкүреш техникасын төзәтү; көнкүреш техникасын төзәтү; компьютерларны һәм перифериядәге компьютер җиһазларын төзәтү; коммуникация җиһазларын төзәтү; күчермә алу-күбәйтү хезмәтен күрсәтү буенча эшчәнлек; фотография өлкәсендә эшчәнлек | 0,7 |
| | – душлар һәм мунчалар (39 урынга кадәр кертеп) сауналар хезмәте; халыкның шәхси заказы буенча солярийлар хезмәте | 1,0 |
| | – душлар һәм мунчалар (39 урыннан да артык) хезмәте | 0,2 |
| | – җирләүне оештыру һәм аның белән бәйле хезмәтләрне күрсәтү | 0,2 |
| | – көнкүреш хезмәтенең башка төрләре | 0,5 |